**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы территориясендә 1 төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
1)Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан су башнясының хуҗалык корылмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) янгын ранецлары (2 данә), су салу өчен емкость (1 т), янгын җиңсәләре (2 данә)сатып алу;
3)кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) Мортыштамак авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары (бензин), хуҗалык эшләре өчен инвентарь (көрәк, тырма,сәнәк, себеркеләр) сатып алу;
5) Мортыштамак авылы Совет урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт сатып алу ,ташу,чокырларга асфальт түшәп ремонтлау, асфальт җәю, эш өчен түләү);
6) Мортыштамак авылында Минзәлә елгасы аша салынган күперне ремонтлау (буяу сатып алу);
7) Мортыштамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
8) Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан зират территориясендәге биек агачларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрдән чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

9) ял итү зоналарын төзекләндерү (Мортыш елгасы һәм Бөек Ватан сугышында һаләк булган авылдашлар өчен куелган обелиск янында эскәмияләр, урналар сатып алу һәм урнаштыру ;
10) яңа юл билгеләре урнаштыру өчен металл торбалар сатып алу;
11) Мортыштамак авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу.

3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Н.Хадиуллин